ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» февраль 2026 ел № 134

**Хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны узу урыннарын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 статьясының 1 өлеше, 50 статьясының 1 өлеше һәм Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 статьясының 1 өлеше, 39 статьясының 1 өлеше нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы составына керүче, җирле үзидарә органнарында алар үтә торган мәҗбүри эшләр төрләренең һәм җирлекләрнең кушымтада бирелә торган исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Россия Җәзаны үтәү федераль хезмәте Баш идарәсе җинаять-башкарма инспекциясенең федераль казна учреждениесе Арча муниципальара филиалына хөкем ителгәннәрне төзәтү һәм мәҗбүри эшләргә әлеге карар белән билгеләнгән урыннарга җибәрүне тәкъдим итәргә.

3. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 5 майдагы "Хөкем ителгәннәр өчен төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү урыннарын билгеләү турында" 406 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э. Ш. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Л.И.Абдуллин

Арча муниципаль районы башкарма
комитеты карары белән

**РАСЛАНГАН**

«___»________2026 ел № ___

**Арча муниципаль районы составына керүче, җирле үзидарә органнарында үтә торган мәҗбүри эш төрләре һәм җирлекләр**
**ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Авыл җирлеге исеме | Эш төрләре |
|---|---|---|
| 1. | Апаз авыл җирлеге | - шәһәрне һәм авыл җирлекләрен төзекләндерү буенча ярдәмче эшләр;<br>- территорияләрне җыештыру;<br>- ярдәмче эшләр. |
| 2. | Кәче авыл җирлеге | |
| 3. | Наласа авыл җирлеге | |
| 4. | Яңа Кишет авыл җирлеге | |
| 5. | Яңа Кырлай авыл җирлеге | |
| 6. | Яңа Кенәр авыл җирлеге | |
| 7. | Урта Курса авыл җирлеге | |
| 8. | Иске Кырлай авыл җирлеге | |
| 9. | Иске Чүриле авыл җирлеге | |
| 10. | Урта Аты авыл җирлеге | |
| 11. | Сеҗе авыл җирлеге | |
| 12. | Ташкичү авыл җирлеге | |
| 13. | Үрнәк авыл җирлеге | |
| 14. | Утар-Аты авыл җирлеге | |
| 15. | Шушмабаш авыл җирлеге | |
| 16. | Яңасала авыл җирлеге | |
| 17. | “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге | |